

С. Я. Маршак


# МИСТЕР ТВИСТЕР

16 тиен.

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ 1972


С. Я. МАРШАК

# МИСТЕР ТВИСТЕР



Р2 7-6-2
М28 145-72М

Төзүчесе Е. Г. АНТОНОВА
Редакторы РЕЗЕДА ВӘЛИЕВА
Художнигы С. М. ҠУЛЬБАҠА



# ТЫҢҒЫ БАБАЙ

Әкият

Йоҡы ул әкрен генә
Ярыктан килеп керә.
Һәм кергән һәрбер өйгә
Шәп төшләр алып килә.

Күрсәтә ул әкиятләр,
Тик аны күрми һәркем.
Күзең ныграк йомсаң әгәр,
Күрерсең син дә, бәлкем!

Әгәр йоклата алмаса
Берәүне Йокы агай,
Килә дә түшәккә сала
Абыйсы — Тынгы бабай.

Син дә йокла инде, җитәр!
Юкса, Тынгы алып китәр!

Троллейбус һәм трамвайлардан
Бушатып урамнарны,
Куа паркларга табан
Тынгы хәзер аларны.

— Барыгыз, ди, йоклагыз,— ди, —
Иртән торып чыгарсыз! — ди.
Исни-исни машиналар
Өйләренә ашыгалар.

Кайда, кем тавыш куптара,
Тынгы бабай шунда бара.
Кем белми һич тынгылык,
Тындыра Тынгы шундук.

Йөри Тынгы бар җирдә дә,—
Авылда да, шәһәрдә дә.
Чакырып ул йокларга,
Керә пароходларга.

Төнлә поезд барганда,
Керә поездларга да.
Тик ятмаган балалар
Шундук тынып калалар.



Була ул һәр йорт эчендә,
Оча җир шары өстендә,
Утырып самолетларга...
Пассажирларга да төнлә
Кирәк чөнки йокларга.

Моторлар гүләвен тыңлап,
Зәңгәр лампа кабызып,
Йоклый кешеләр тынычлап,
Болытлар аша узып.

Тынгы бабайга бер заман
Әйтә берәү телефоннан:

— Кил әле безнең урамга,
Зинһар, дим, Тынгы бабай.
Теләми һич тә йокларга
Антон атлы бер малай.

Аңламый тиргәгәнне дә,
Көлә тик — чырык-чырык.
Йоклатмый бүтәннәрне дә,
Я көлеп, я кычкырып.
— Тукта инде, җитәр! — дибез. —
Тынгы алып китәр! — дибез.

Шуннан соң да туктамый:
Куркытмагыз юкка! — ди. —
Килсен әле, шунда без,— ди,—
Кем көчлерәк, күрербез! — ди.

Йокларга яткан бар да:
Зурлар да, балалар да.
Карлыгач та, фил дә йоклый,
Тик Антон: «Йокламыйм, юк!» — ди.

Караңгыда кроватьта
Барын да ишетеп ята:
Кемнәр ничек йоклаганны
Һәм ничек сулыш алганны,

г-45—2



Сәгать ничек йөргәнне,
Этләр ничек өргәнне.
— Йокла инде! — ди әнисе.
Аңарга да китми исе.

Шул чагында яңгыратып
Сәгать суга кинәт кенә.
Шул чагында, ишек ачып,
Тынгы бабай килеп керә.

Килә дә Антон янына,
Иелә кроватена.

Үзенең кулында бар
Җепкә таккан зәңгәр шар.
Бер баксаң, ул шар да кебек,
Бер баксаң, фонарь да кебек.

Эчендә ут янып тора.
Үзе сөйли акрын гына:

— Бер. Ике. Өч. Дүрт. Биш.
Йокла, малай, тиз бул, тиз!
Кем теләми тынарга,
Чыгып китсен урамга!

Кинәт шул фонарь сүнә дә,
Ишекләре ачыла.
Пырхылдап аннан бүлмәгә
Кошчыклар очып чыга.

Бөтен бүлмәдә шулар
Очып йөри башлыйлар.

Пышылдап сорый малай:
— Берсен бир миңа, бабай!

Тынгы әйтә:— Аларны бит
Син күрәсең төшендә тик.



Йоклыйсың бит инде син,— ди.—
Үзен генә белмисең! — ди.

Урман эче. Тынгы бара,
Ай нурына уралып.
Аз түгел бит урманда да
Тынгы белмәгән халык.

Урман йоклый. Тик кайчак
Кыштырдап куя яфрак.
Куаклар селкенеп китә:
Тынгы бабай моннан үтә.
Кисәтә кош балаларын
Анда ул: — Йоклагыз, — ди. —
Айлы төннәрдә сез һич тә
Оядан чыкмагыз! — ди. —
Төннәрен чыгып йөрсәгез,
Хәтта якында гына
Мөмкин, ди, эләгүегез
Ябалак тырнагына...


Кая барса Тынгы бабай,
Шунда бара Йокы агай.
Төнлә алар бар җиргә
Баралар икәү бергә.

Чакрып алалар көндезен
Кайчак Тынгының берүзен.

Бу нинди тавыш мәктәптә?
Сәбәбе нәрсә? Кем әйтә?

Бер сәгать инде менә
Беренчеләр шау килә.
Ә сәбәбе аның шул,
Сәмиттән башланган ул.

Бүген ул дежурный икән,
Шунда: — Шауламагыз! — дигән.



— Шауламагыз! — дигән Әхмәт,
Аңарга кушылган Рәхмәт.


— Туктагыз! — дигән Галимә,
Аңа кушылган Сәлимә.

Аңарга кушылган Вәли,
Миша, Валя, Шура, Гали.

— Шауламагыз, җитәр! — дип
Акырган шунда Казбек.

Ә җыр укытучы апа
Нишләргә дә белмәгән,
Хәтта классны ташлап та
Чыгарга ул теләгән...

Шунда Тынгы килеп кергән,
Класстагы хәлне күргән.
Усал гына караган да
Тынгы бабай болай дигән:
— Бүтәннәрне өйрәткәнче,
Үзең шауламаска өйрән!



# ФРОНТ ПОЧТАСЫ

1

Кем бу ишекне кага?
Каеш сумка аркада.

Миңа кирәк кеше бу:
Шул үзе, әлбәттә, ул —
Ленинград буенча
Хат ташучы почтальон.

Туганнарча күрешеп,
Бер-ике сүз әйтүдән
Аңлап алдым: якташым
Элеккечә көр икән.

Семьясы да сау-исән.
Авыр чак инде артта.
Тырыш хезмәте өчен
Медаль биргәннәр картка.

Ул саклаган шәһәрне —
Безнең Ленинградны,
Очса да снарядлар
Һавада бер-бер артлы.

Егерме еллап элек
Ничек булса, ул һаман
Сумкасына хат төяп
Уза безнең урамнан.

2

Кем бу ишекне кага?
Сумка бавы аркада,
Зәңгәр фуражка кигән,
Бакыр бляшка элгән.

Бу — шул үзе, һәрвакыт —
Яз да, көз дә, кыш та ул —
Ленинград буенча
Хат ташучы почтальон!

Егерме ел элгәре
Мине ул нәкъ шулай ук
Уята торган иде
Шылтыратып звонок.

Күпме тапкыр мин аны
Иртәнге аулак чакта
Җәяү очратканым бар
Безнең йорт торган чатта.

Яңгырмы ява анда,
Кармы тузгый буранда,
Ул һаман сумка тагып
Йөри иде урамда.

Егерме йортка тиеп
Үтә иде көн саен,
Иң азакка калдырып
Инженерлар сараен.

Тора иде ул чакта
Минем белән бер катта
Борис Житков — җан дусым
Һәм яраткан язучым.

Диңгез штурманы ул,
Гизде бөтен дөньяны.
Җир шары буйлап шуннан
Хат килде эзләп аны.

Хат килде илләр гизеп,
Дәрьялар, чүлләр кичеп,
Кораб бүлмәләрендә,
Һава көймәләрендә.

Ул хат очып үткән, ди,
Эссе яклар буенча,
Күргән, ди, ул: бегемот
Ничек итеп су эчә.

Күргән фламингоның
Ничек канат юганын
Һәм кенгуру артыннан
Динго эте куганын.

Ниһаять, килеп житте
Ул хат Ленинградка.
Төрле марка — тамгалар
Сугылган иде хатка.



Бусы — Дублин, Эйреда.
Бу утрау — Тринидад,
Бу — Рио де Жанейро,
Сан-Франциско,
Ленинград.

Иптәш Житковка аны
Тапшырды, әлбәттә, ул —
Ленинград буенча
Хат ташучы почтальон.

3


Ростов, Тула, Казанда
Туып үскән балалар
Житков турында язган
Хикәямне беләләр.

Иптәш Житков юк хәзер...
Минем яшь укучылар —
Хәзер инде фронтта
Данлыклы сугышчылар.

Ут эченнән аларга
Маркасыз да бара хат.
Иң кадерле бүләктән
Һәр сүзе аның кыйбат.

Ак канат та күк канат,
Кошлар кунган шикелле,
Килеп төшкән хатларның
Һәрбер юлы сөйкемле.

Хат язалар әниләр,
Хат язалар нәниләр.
Якын кешеләренә:
— Күптән күп сәлам, — диләр.



Фронт юлы буенча
Илдән хәбәрләр оча,
Хатлар килә һәркемгә,
Терегә һәм мәрхүмгә.

Җиңү шатлыгы белән
Туган саен яңа көн,
Ераккарак илтәләр
Һәркемнең язган хатын.

Бик ихтимал шундый хәл:
Иптәш Житков улына
Дигән хатны Берлинда
Тапшырырлар кулына.

Кичә дары төтене
Бу җирдә кайнап торган.
Хәзер фронт почтасы
Шунда чатырын корган.

Сөйләшәләр безнеңчә —
Рус, татары аралаш.
Кемдер уйный гармоньда.
Повар булә кайнар аш.

Украина җиреннән,
Бакчалар арасыннан
Безнең танклар бара,
Корыч крепость сыман.

Тиздән фронт почтасы
Хатлар төяп озатыр.
Хат тапшырыр батырга
Почтальон — үзе батыр.

Яшерен сукмак буенча,
Тау буеннан, урманнан
Рота һәм батальонга
Хат илтүче почтальонга
Бездән рәхмәт, бездән дан!

Каешлы сумка тагып,
Безнең ишекне кагып,
Әтиләр, абыйлардан
Хат алып килүчегә
Бездән рәхмәт, бездән дан!

4

Көньяктагы шәһәрнең
Шундый эссе һавасы.
Ә еракта ялтырый
Кар каплаган тау башы.

Агач күләгәсендә,
Салкын чишмә буенда,
Шау-гөр килеп балалар
Бирелгәннәр уенга.

Чынлап сугышкан төсле,
Чишмәне кичеп алар,
Каршы ярдагылардан
Берсен плен алганнар.

Шул чагында почтальон
Килеп чыга каршыга.
— Бармы әллә безгә хат? —
Дип сорыйлар барсы да.

— Бүген,— ди ул,— китердем
Хат ике фатирчыга:
Егерме бишенчегә,
Егерме алтынчыга.

— Без бит шунда торабыз.
Бирегез безгә аны!
— Укый алырсыңмы соң?
— Таныйбыз әлифбаны.

Югары кат баскычтан
Хат алырга төштеләр.



— Петровларга әткәсе
Хат җибәргән ич! — диләр.

Күрсә әгәр еракта
Бу бакчаны, бу өйне,
Нинди куаныр иде
Петров — полк герое.

Нефть складында
Хезмәт итеп ул элек,
Яши иде шушында,
Әкият багында кебек.

Ял көннәрен каршылап
Семьясы белән шунда,
Утыра торган иде ул
Үзенең баскычында.

Кайда соң ул? Сугышамы
Фронтта көндез-кичен?
Башын салдымы әллә
Туган-үскән ил өчен?

Кем белсен. Хат буенча
Билгеле тик шундый хәл:
Сержант Петров сау булган
Өч атна моннан әүвәл...

5

Басма хәрефләр белән
Улы язды сәлам хат.
Кызы исә актыктан
Өстәде бер юл фәкать.

Малай язды: «Гафу ит
Болай итеп язганга.
Фашистларны ку да син,
Кайт тизрәк безнең янга.





Сугыш хәле турында
Тулы яз, барсын белим:
Кайда торасың анда?
Күпмесен алдың плен?

Сезнең батареяда
Туплар күпме, әллә аз?
Секрет булмаса әгәр,
Шул турыда тизрәк яз.

Бер көн радио тыңлыйм:
Приказ, аннан соң Гимн,
— Бу минем әткәй керде
Молодечнога! — димен.

Мин дә синең шикелле
Батыр булырмын алда.
Курыкмыйча мин хәзер
Карыйм төнлә урамга.

Бер ел инде еламыйм.
Мин бит инде дәү генә.
Хатың килгән көннәрдә
Елый тик әнкәй генә.

— Ул бит тере, ул исән,
Елама, әнкәй! — дисәм,
— Мин елыйм, ди, бәхеттән,
Исән булганга әткәң.

Кинода бер сугышчы
Сиңа шундый охшаган.
Хуш хәзергә. Тон җитте.
Көтәм сине.

Сережаң».

Төнге караңгыда ул
Куйды хатка ноктасын,
Кызы да бер юл өстәп
Язды сагынып әткәсен.

Иртә белән, иртән үк
Язды болай дип аңа:
— «Сау бул. Кыйна дошманны.
Көтәмен.

Светлана».

6

Зур бер станциядә
Төрле якның хатлары
Поезд көтәләр иде,
Җыйналып бергә бары.

Шыпырт кына үзара
Сөйләшәләр:
— Кем кайда?
— Киров,
— Горький,
— Боровой,
— Кызыл Орда,
— Караганда...

Поезд килгәнче алар
Сумкада, күн букчада,
Сөйләштеләр һәр телдә —
Русча да, калмыкча да...

Кешеләрчә кычкырып
Сөйләшмиләр, әлбәттә.
Язылган бит ул сүзләр
Адрес итеп һәр хатта.

Һәрбер хат юлын белә:
Кайсы шәһәр, кай район,
Кайсы номер капканы
Ачып керер почтальон.

Бары тик сугышчылар
Сагынып хат көткән урын
Кайсы йортта?



Һичбер кем
Язмый аның номерын.

Төнлә поезд туктый да:
— Төшегез! — диләр.— Фронт!
Күктә яшен шикелле
Уйнап тора зәңгәр ут.

Самолет тавышы килә.
Безнекеме? Түгелме?
Әллә дошман ягымы?
Көтеп торыр чак түгел.
Бушат әйдә вагонны!

Яшерен сукмак буенча,
Тау буеннан, урманнан,
Ротага, батальонга
Хат илтүче почтальонга
Бездән рәхмәт, бездән дан!

Каешлы сумка тагып,
Безнең ишекне кагып,
Әтиләр, абыйлардан
Хат алып килүчегә
Бездән рәхмәт, бездән дан!

7


Иң гади бер кеше ул —
Ротаның почтальоны.
Шулай да чиксез озын
Аның үтелгән юлы.

Траншеяга хәтле
Өч йөз адым юл бары,
Дошман уты астында
Үтә ләкин ул аны.

Мылтык ядрәсе килеп,
Баш очында сызгыра.
Юлда авыр снаярд
Чокырлар казып тора.

Ут яңгыры астында
Килми тиккә үләсең,
Кайда шуып, иелеп,
Кайда йөгереп үтәсең.

Туплар шартлый якында.
Туфрак катыш ут ява.
Ике туры ат дулый
Йөгән тартып уртада.



Почтальон сыйпап уза
Ул атларның ялларын:
«Тынычлык юк сугышта
Сезгә дә, дип, җаннарым!»

Тузан куба... Күл тула
Почтальон күзләренә.
Күрә: туры атларның
Юк инде эзләре дә...

Учында сизә әле
Аларның җылысын ул...
Әйтерсең сезне, атлар,
Очыртып китте давыл...

Өч йөз адым чамасы
Ул барасы окопка...
Ләкин сугыш кырында
Юл озая бик күпкә!

Йөри торгач почтальон
Эзләп таба танышын.
Егетләрчә куя ул
Төзәткәләп каешын.

Бары да исәнләшә:
— Бик сау килдеңме? — диеп,
— Петров кайда?
Я, Петров,
Хатны ал әле биеп!

Кызу бүген, нәкъ мунча.
Шулай да җиңел, рәхәт —
Куен кесәндә булгач
Туган илдән килгән хат!

8

Җиңү шатлыгы белән
Туган саен яңа көн,
Еракларак илтәләр
Һәркемнең язган хатын.

Батыр сугышчылардан
Калмыйча бер адым да,
Ут астында почтальон
Һаман бара алында.

Яшерен сукмаклар буйлап,
Тау буеннан, урманнан,
Ротага, батальонга
Хат илтүче почтальонга
Бездән рәхмәт, бездән дан!

Каеш сумкасын тагып,
Безнең ишекне кагып,
Әтиләр, абыйлардан
Хат алып килүчегә
Бездән рәхмәт!
Бездән дан!



# ТЕГЕРМӘНЧЕ БАБАЙ, ИШӘК ҺӘМ МАЛАЙ

(Көнчыгыш әкияте)

1

Бара, ди,
Бабай
Ишәктә
Иплэп;
Чаба, ди,
Малай
Җәяү
Тәпиләп.


Икәү
Менгәннәр
Сыңар
Ишәккә!

4

Җиргә
Төшәләр
Бабае,
Улы.
Ишәк
Атлана
Картка
Бу юлы.
— Тфү! — ди
Барысы,

Бу эшне
Күреп,
— Карт ишәк
Илтә
Яшен
Күтәреп!

Кемнәр
Ишеткән?
Күр инде,
Кара! —
Карт
Ишәк
Яшен
Күтәреп
Бара.





# МИСТЕР ТВИСТЕР

1

Кукның
Конторы
Бар, ди,
Чит илдә.

Эчегез пошып
Сезнең, әгәр дә
Барасыгыз килсә
Бер җиргә —
Таити утравына,
Парижга,
Яки очып
Памир тавына, —

Шул минуттук
Сезнең өчен
Кук
Хәзерләтер
Қораб каютын,

Я җибәртер
Һава көймәсен,
Иярләтер
Атын,
Дөясен.

Урнаштырыр
Яхшы отельгә,
Иртәнге аш
Бирелер постельгә.

Урманнар һәм таулар арасын,
Чикләвек һәм пальма агачын,
Җирнең җылы,
Салкын якларын, —
Кук күрсәтер сезгә ни барын.

2

Мистер
Твистер —
Булмыш министр,
Мистер
Твистер —
Банк иясе,

Пароход, завод,
Газет хуҗасы, —
Аның да килә
Дөнья гизәсе.

Хатынын, кызын
Барырга димли, —
Хатын бик риза,
Қыз —
Қаршы килми.

3

Иртәнчәк
Кукка
Телефон аша
Қемдер эндәшә:
— Дүрт кают кирәк
Нью-Йорктан
Ленинградка!
Ванналы,
Заллы,
Фонтан,
Бакчалы
Номер алсыннар.
Тик карасыннар:
Негр,
Қытайлар
Була күрмәсен
Аңар күршедә;
Мистер
Аларның
Сөйми берсен дә.

Кук
Телефоннан
Белдерә:
— Ярый!
Теләкләрегез
Үтәлер бары.



4

Қораб китәргә
Ун минут
Қалгач,
Твистер килде.

Янында —
Қартлач
Хатын күренде,
Күзлек кигән ул.
Қызы кулында —
Бәләкәй маймыл.

Алар
Артыннан
Дүрт егет килә,
Егерме дүрт зур
Чемодан белән.

5

Пароход йөзә
Зәңгәр диңгездә,
Америкадан
Қилә ул безгә.

Қөнчыгышка ул
Туп-туры бара.
Қорма артында
Океан
Чайкала.

Мистер
Твистер —
Булмыш министр,
Мистер Твистер —
Банкир,



Байгура,
Океан өстендә
Туп уйнап бара.
Якын-тирәдә
Кара тәнлеләр:
Негр,
Кытайлар
Һәм башка шундый
Төрле халык юк, —
Негр,
Кытайны
Һәм башкаларны
Дулкында чайкый
Бүтән пароход.
Аларга кайда
Рәхәт бу төсле?
Негр, кытайга
Юеш һәм эссе, —
Морҗадан чыга
Төтен кап-кара,
Өскә тозлы су
Дулкын актара.

Күктә болытлар —
Корым аралаш.

Эшләпә читен
Тотты да
Мистер,
Траптан йөгереп
Чыкты:
Пристань.
Петропавелнын
Гөмбәз башына
Күз төшергәнче,
Килде машина.
Төялде әйбер,
Ханымнар мендe.
Автомобиль бер
Усал үкерде, —
Һәм алып китте
Такыр асфальттан,
Җәяүлеләрне
Бензинлап арттан.

6

Мистер Твистер —
Миллионер.
Совет илендә
Турист ул хәзер.

Ленинград порты
Шаулый
Ерактан.
Шәһәр йортлары
Балкый
Уң яктан;
Сулары соргылт,
Колоннасы таш,

7

Мистер
Твистер —
Булмыш министр,
Мистер
Твистер —
Миллионер, —
Завод, пароход,
Газет хуҗасы,
«Англетер»гә
Килеп керде дә,
Сорады номер.

Алтын сигара
Авызында көйри,




Швейцар белән
Инглизчә
Сөйли:
— Бармы номерлар
Сезнең отельдә?
Хәбәр ителде
Кичә үк сезгә.
Мыеклы абзый
Җавап бирә:
— Бар!
Тугыз белән ун —
Сезнең номерлар.

8

Көзгеләр буйлап
Номерга табан
Үттеләр алар
Хәтфә паластан.

Швейцарында —
Укалы кием,
Аның артында,
Панамын киеп,
Атлый юлчыбыз,
Аның артында —
Күзлекле хатын,
Ияргән тагын —
Маймыл тоткан кыз.

Юлчылар
Никтер
Шашып калдылар, —
Мистер
Твистер
Төште кайгыга.



Йөз туксанынчы
Номердан
Төшеп
Килә
Зур буйлы,
Кап-кара
Кеше.

Баскычны тоткан,
Кулы
Кап-кара.
Трубка тартып,
Ашыкмый бара.

Ә көзгеләрдә
Әллә нихәтле
Кара негрлар —
Кара кешеләр,
Берсе-берсенә
Ияргән килеш,
Түбән төшәләр;
Һәркайсы
Баскыч
Кырыен тоткан.
Һәркайсы
Кыска
Трубка
Капкан.

Мистер
Ачуын
Йота алмады.
Уңга
Каранды,
Сулга
Каранды:

— Кара негрлар
Торган чагында,
Һичбер ничек без
Калмыйбыз монда!
Панамлы юлчы,
Эре-эре
Атлап,
Йөгерә
Баскычтан
Түбәнге
Катка.
Артта —
Карчыгы,
Күзлек кигән ул;
Артта —
Теге кыз,
Кулында маймыл.

Автомобильгә
Менделәр тып-тын.
Карчык шоферга
Төртте зонтигын.

Швейцар чыгып
Саубуллашты да,
Телефон аша
Кычкырды шунда:

— Ике
Кырык ике
Кырык сигез,
«Астория»ме?
Швейцар Григорий
Хәзер андамы?

Тыңла, Григорий!
Әзер килеш тор:
Бездән китteләр
Өчәү —
Твистер.



Ул бәйләнчекләр
Барсалар сезгә,
Җавап хәзерлә:
— Урын юк,— диген,
Аңладыңмы син?
Сау бул хәзергә!

— Егерме бер
Унсигез,
«Сицилия»ме, ә?
Швейцар Василий
Бик кирәк миңа.
Тыңла, Василий!
Сиңа йомыш бар:
Автомобильдә
Барса туристлар,
Өчәү —
Твистер.

Ул җәнҗалчыга
Җавап хәзерлә:
Номер юк, диген,—
Аңладыңмы син?
Сау бул хәзергә!

Биш
Утыз биш
Утыз тугыз,
«Италия»ме?
Чакыртыгыз
Швейцар Виталийны.
— Саумы, Виталий?
Эш бар бит синдә:
Барса туристлар
— Юк, диген, бездә...

. . . . . . . .



9

Өерә урамда
Тузаннарны җил,
Йөгерә урамда
Бер автомобиль.

Гоголь урамы,
Өченче капка,
— Килдегез,— диләр,—
Номер юк чакта.

Пестель урамы,
Беренче капка,
— Килдегез,— диләр,—
Урын юк чакта.

Ирек мәйданы,
Бишенче капка,
— Бүлмә юк,— диләр,—
Бездә бу чакта.

Шартлап ярылды
Уң яктагы
Шин,
Җитмәстер, ахры,
Моторга
Бензин.

10

Мистер
Твистер —
Булмыш министр,
Мистер
Твистер —
Атаклы банкир,
«Англетер»гә
Карчыгы белән
Кире кайтты ул.

Артында — кызы,
Кулында маймыл.
Бикле ишеккә
Мистер
Кагылды.
Коридор буйлап
Утлар кабынды.
Сәгать чыңлады
Унике тапкыр.
Швейцар торып
Ишекне ачты.
Озын мыегын
Сыйпап алды да,
Килеп туктады
Алар алдына.

— Соңга калдыгыз!
Бая әйтелгән
Ике номерга
Кеше кертелгән.
Хәзер, беләсез,
Ерак-еректан —
Колонияләрдән
Безгә съездга
Килде кунаклар.
Шушы кунаклар
Төштеләр монда,
Бөтен номерлар
Алар кулында.

Кызы инәлде:
— Нишләргә инде?
Ардым шул хәтле.
Кунарга рәтле
Урын әгәр дә
Табылмый икән,
Сатып ал, әткәй,
Бер йорт
Шәһәрдә!




Мистер
Твистер,
Ачуы килеп,
Әйтте кызына:
— Чикаго түгел,
Кызым, бу сиңа!

11

Аналы-кызлы
Истән аварга
Торганда гына,
Швейцар аларга
Бирмәкче булды
Үз кроватен:
— Ханымнар шунда
Йокларлар ятып!

Ә мистер
Шуннан,
Ишек каршыннан
Урындык алды.
Аркасын сөяп:
— Уф, алла! — диеп,
Йокыга талды.
Совет номеры —
«Англетер»нең
Бусагасында
Йоклап китәрен
Уйламагандыр
Әлек ул һичбер,
Мистер
Твистер —
Булмыш министр,



Мистер
Твистер —
Миллионер.

Елмайды кинәт
Ул йокы катыш,
Күрә башлады
Гаҗәп
Кызык төш.

Күрә төшендә,
Караңгы төндә
Урамнар буйлап,
Йорт-җирсез сукбай
Булып ул үтә.
Оча самолет
Биектә — күктә,
Һәм күктән җиргә
Кук килеп төшә.

Твистер аны
Барып кочаклый,
Кулларын кыса
Әллә ничаклы.
Менеп ала да
Самолетына,
Каты иттереп
Ишеген яба,—
Очып китәләр
Зәңгәр һавага.
Менә җитәләр
Америкага.

Мәрмәрдән салган
Йортлар —
Чикаго!
Картайган лакей
Кычкырды
Шундук:
— Сезгә урын юк
Америкада!

Имән ишекләр
Ябылды түрдә.
Ул күрде үзен
«Англетер»дә.

Куркып уянды:
— Нихәл итәрмен?..
Совет номеры
«Англетер»нең
Бусагасында
Төнен үткәрде —
Мистер Твистер —
Булмыш министр,
Мистер Твистер —
Миллионер.

12

Көләч бер малай,
Щетка тотып,
Йокыны ачты,
Итек чистартып.
Алдында аның
Һәртөрле якның
Аяк киеме —
Тары һәм киңе.

Советныкылар,
Шведныкылар,
Француз, немец,
Һәртөрле җенес...
Куйган срокка
Чистартты барын —
Төрле төстәге
Щеблитлар парын.

Соңгы щеблитны
Ялтыратуга —
Күрде:




Чит кеше
Күзләрен уа.
Менә ул торды,
Алды портсигар.
Кинәт контордан
Чыкты швейцар.

— Булды! —
Диде ул, —
Сезгә урын бар,
Икәү янәшә,
Бик шәп номерлар, —
Ванналы, заллы,
Фонтан,
Бакчалы.


Теләсәгез, мин
Хәзер күрсәтәм.
Тик алдан сезгә
Мин шуны әйтәм:

Уң як номерда —
Кытай вәкиле,
Сул як номерга
Негрлар килде.
Өске номерда —
Кунак — «Һиндстан»,
Аскы номерга
Килде Тунистан.
. . . . . . . . .
Миллионер
Кулын
Чәбәкләп селки,
Һәм инглизчә
Кычкыра:
— О-кей!
Куанычыннан
Күзе акая:
— Бирегез тизрәк,
Ачкычы кая?!




Маймылын,
Қызын
Қултыкка кысып,
«Англетер»нең
Таныш баскычын
Атлады кызып —

Мистер
Твистер —
Булмыш министр,
Мистер
Твистер —
Миллионер.







# КҮГӘРЧЕННӘР

1.

Без грузовикта Берлинга
Юл барган чакта,
Сөйләде бу хикәяне
Безгә бер якташ.

Әллә чын, әллә әкият,
Әллә әкият тә түгел, —
Ансына да, монсына да
Ышана күңел.

2.

Күк күгәрчен ул тәрәзне
Онытмас һич тә,
Чарлагында ярма чүпләп
Йөргәне истә.

Кәрзиндә алып китсәң дә
Аны ят җиргә,
Сукмаклар табар ул күктә
Кайтырга илгә.

Шундый зирәк кош ул менә,
Үткен күзле кош.
Очуы да гади түгел,
Иң җитез очыш.

Үзенең юлын очучы
Беләә күңелдән,
Тыңләшә алмый шулай да
Күгәрчен белән.

Урман-таулар, диңгезләрне
Ул җиңел үтә,
Бар тамгалы балдагы да,
Кошкай хат илтә.

3.

Карт шәһәрне таптап йөри
Немец итеге.
Урелде күккә янгыннар
Зур дәһшәт сибеп...

Таптады бала-чаганы
Патруль атлары,
Кайнар җилдән дерелдәде
Тал яфраклары.



Урамнарда елау тавышы
Яңгырап торды.
Палач дарга һәм коллыкка
Кызларны куды.

Украина бодайларын
Тутырып-төяп,
Үттеләр чит ил ягына
Вагоннар күпләп.

4.

Немец көн саен бүләкләр
Салды өенә,
Зоопаркта да булды
Бу ерткыч менә.

Алып чыкты ул маймылны,
Юлбарысларны,
Дөяне, ерак иләрдән
Килгән кошларны.

Арсланны, еланнарны
Төяп җибәрде,
Җибәрде гөрләп утырган
Күгәрченнәрне.

5.

Күк күгәрчен айлар буе
Тилмерә читтә.
Ә сугышлар Украинада
Тынмыйлар һич тә.

Сугыш бара Украинада,
Туктаусыз бара.
Немец утлары аркылы
Гаскәр юл ала.



Днепр елгасы шаулы,
Уң яры текә.
Кара төндә Кызыл Гаскәр
Елганы үтә.

Октябрьны бәйрәм итә
Илебез кабат,
Ике бәйрәм бергә быел —
Украина азат.

6.

Фронт хәзер чикне үтеп,
Бик ерак китә.
Төзелеш бара башкалада —
Данлы Киевта.

Зоопаркта да тормыш
Җайланып бара.
Москвадан, Ленинградтан
Бүләкләр ага...

Әйтәләр Казахстанның
Дөя биргәнен.
Әйтә алмыйм филнең генә
Кайдан килгәнен.

Кавказ бөркетләр җибәргән,
Себер — бәланнар.
Курск сандугачлары да
Шунда җырларлар.

Күгәрченнәр чарлагында
Һаман тын иде.
Кошларыбыз чит җирләрдән
Кайтмаслар инде.



Кайтмаслармы?
Ә кайдан соң
Бу шаулау, гөрләү?
Күрәмсең, кунды түбәгә
Күк түшле берәү.

Күктән туп-туры бакчага
Оча җилпенеп,
Сагынып кайткан дусларның
Чуар төркеме.

Бу икесе — кардан аклар,
Ал әнә берсе,
Берсе чуар, берсе зәңгәр,
Тутый кош төсле.


Күгәрченнәр гөлдер-гөлдер
Килеп гөрлиләр,
Сәламләп туган җиркәйне,
Сөенеп йөриләр.

Җиңел канат, күк күгәрчен
Кечкенә генә,
Үзендә күпме кыюлык,
Көч икән менә.

Сөйләгез, кошлар-дускайлар,
Сугыш турында.
Ничек итеп яшәдегез
Ятлар кулында?

Чүлмәк түбәләр астында,
Чикләрдән ары
Кол булган көнегез ничек
Үтте аннары?

Барыгыз да шат идеме
Күзен очарга





Бу кыен һәм куркынычлы
Авыр юлларда?

Ут күзле житез күгәрчен,
Барын да сөйлә —
Кем алып кайтты сезне бу
Кояшлы илгә?

Без грузовикта Берлинга
Юл барган чакта,
Сөйләде бу әкиятне
Безгә бер якташ.



Э Ч Т Ә Л Е К

Тынгы бабай. *Әхмәт Исхак тәрҗемәсе* . . . . . . . . . . . . 3
Фронт почтасы. *Кави Нәҗми тәрҗемәсе* . . . . . . . . . . . . 9
Тегермәнче бабай, ишәк һәм малай. *Кави Нәҗми тәрҗемәсе* . . . 17
Мистер Твистер. *Кави Нәҗми тәрҗемәсе* . . . . . . . . . . . 21
Күгәрченнәр. *Әхмәт Юныс тәрҗемәсе* . . . . . . . . . . . . 33

*КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН*

*Самуил Яковлевич Маршак*

МИСТЕР ТВИСТЕР

(на татарском языке)

Художество редакторы А. Г. Садыйков

Техник редакторы В. Н. Галкинә

Корректоры Д. Н. Миңнуллина

Наборга бирелде 25/I-1972 ел. Басарга кул куелды 17/III-1972 ел. Типография кәгазе № 1, 70×90 1/16. Учетн.-изд. таб. 3,48. Якынча басма таб. 2,94. Тираж 10.000. Заказ Г-45. Бәясе 16 тиен.

Татарстан китап нәшрияты, Казан, Бауман ур., 19.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, 19